МБГББУ" ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БУА ШӘҺӘРЕ 5 НЧЕ ГИМНАЗИЯ"
МӘКТӘП ГАЗЕТАСЫ

# ТАМЧЫ

№1-2025

## 1 сентябрь-Белем көне белән!




Белем көне – мәктәп бусагасын тәүге тапкыр атлап керүче балалар өчен дә, чыгарылыш сыйныф укучылары өчен дә, педагоглар, тәрбиячеләр өчен дә дулкынландыргыч вакыйга.

Быел беренче мәртәбә парта артына утыручылар тырышып укысын, бетмәс-төкәнмәс белем хәзинәләрен ачсын. Кайгыртучан укытучыларыбызга изге эшләрендә уңышлар һәм сабырлык юлдаш булсын. Әлеге катлаулы, ләкин шул ук вакытта мавыктыргыч дөнья сезнең барыгызны да шат елмаюлар, кызыклы танышулар һәм иң мөһиме–төпле белемнәре белән каршы алсын.

"Беләкле берне егар, белемле меңне егар", - ди татар халык мәкале. Элек-электән татар милләте укымышлы, китаплы булуы, белемгә тартылуы белән аерылып торган. Алга таба да шушы кыйблабыздан тайпылмыйча, киләчәк өчен кирәкле һөнәрләр сайларга, илебезгә файдалы шәхес булып җитлегергә насыйп булсын.

Кадерле дуслар! Көзнең тәүге бәйрәме – 1 сентябрь сезнең барыгызга да муллык һәм иминлек алып килсен. Яңа уку елы югары нәтиҗәләргә бай булсын!





## ХӘТЕРНЕ ЯХШЫРТУ ӨЧЕН КҮНЕГҮЛӘР



Озын җәйге каникуллардан соң укуга кереп китү җиңел түгелдер, шулаймы? Хәтерне яхшырту өчен сезгә түбәндәге күнегүләрне тәкъдим итәбез:

– һәр хәрефкә сүз әйтеп, алфавитның бар хәрефләрен тиз генә кабатлап чыгыгыз (а-алма, б-балта...);
– бер хәрефкә башланган 20 сүз әйтегез һәм аларны номерлап барыгыз (1 – күлмәк, 2 – китап, 3 – кунак...);
– бер минут элек, бер сәгать яки кичә нәрсә эшләгәнегезне, соңгы өч көндә иртән нәрсә ашаганыгызны искә төшерегез;
– әгәр уң кулыгыз белән язсагыз, сул кул белән язып карагыз, ә сулагайлар, киресенчә, уң кул белән языгыз;
– караңгы бүлмәдә йөреп карагыз, ул хәтерне, игътибарны арттырыр;
- кибеткә кергәч, калькулятор кулланмагыз. Хәтердән генә кушу, алу баш мие эшчәнлеген яхшыр-тыр;
-бию, физик күнегүләр ясау, йөгерү баштагы кан әйләнешен яхшырта;
-телефонга хайваннар турында табышмаклар, география, сәнгать белән бәйле кушымталар йөкләп куегыз. Көненә 15-30 минут шундый биремнәр үтәү баш мие өчен бик файдалы.

# ӘДӘБИ БИТ

## Танылган татар балалар язучысы Абдулла Алишның тууына 117 ел (1908-1944)



**Абдулла Алиш** (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) – татар балалар әдәбиятының якты йолдызы. Ул 1908 елның 15 сентябрендә Спас районының Көек авылында дөньяга килә.

Әдәбиятка мәхәббәте мәктәп елларында ук башлана: драма түгәрәкләре, стена газеталары, кульязма журналлар… һәм, әлбәттә, үзенең беренче хикәяләре.


Язучы балалар өчен дә, олылар өчен дә иҗат итә. Әмма аны халыкка иң нык таныткан әкият-хикәятләре «Нечкәбил», «Сертотмас үрдәк», «Чуар тавык», «Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык» кебек әсәрләр яшь буынга акыл һәм тәрбия биреп килә. Күпсанлы әкиятләре гади, балаларга аңлаешлы тел белән язылган.

1941 елда Алиш фронтка китә, соңыннан әсирлеккә эләгә. Әмма хәтта авыр шартларда да ул иҗат итүдән туктамый, шигырьләр яза. Фашизмга каршы тиңсез батырлыгы өчен ул үлгәннән соң I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

Абдулла Алиш – балаларга әкият бүләк иткән, тормышын Ватанга багышлаган батыр шагыйрь.


Абдулла Алиш, чыннан да – безнең арада, үз халкына хезмәт итә, якты образы белән яшь буында батырлык һәм гаделлек үрнәкләре, туган илебезгә һәм туган телебезгә мәхәббәт тәрбияли.


**Абдулла Алиш әкиятләре**













---




## *18 сентябрь Татарстан Республикасының халык язучысы Гариф Ахуновның тууына-100ел! (1925-2000)*

**Гариф Ахунов** 1925 елның 18 сентябрендә Татарстанның Арча районы Кече Өчиле авылында (хәзерге вакытта ул авыл юк) крестьян гаиләсендә туа.

**Гариф Ахуновның** проза әсәрләреннән күбесе русчага тәрҗемә ителә, хикәя һәм повестьлары украин, үзбәк, кыргыз, мари, чуаш, якут һ.б. телләрдә басыла, «Хәзинә» романы казакъча һәм төрекмәнчә тәрҗемәдә нәшер ителә.


Әдәбият өлкәсендәге казанышлары һәм иҗтимагый тормыштагы актив эшчәнлеге өчен Гариф Ахунов 1975 елда Хезмәт Кызыл Байрагы, 1981 елда Халыклар Дуслыгы орденнары белән бүләкләнә, 1972 елда аңа «Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә, ә 1993 елда Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев Указы белән ул «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мәртәбәле исемгә лаек була. Әдип шулай ук 1998 елдан Татарстан Фәннәр академиясенең "Шәрәфле академигы" дигән мактаулы исем йөрткән.

Гариф Ахунов 2000 елның 4 июнендә Казанда вафат була.















## 10 сентябрь – төрле төстәге чәчәк бәйләмнәре көне

Бактың исә, чәчәкләр буенча да йолдызнамәләр була икән. Үзегезгә нинди чәчәк туры килүен карагыз әле.

**Кучкар** йолдызлыгында туучылар якты төстәге чәчәкләрне үз итәчәк. Кызыл, кызылт-сары төстәге розалар, гладиолуслар, маргаритка кебек чәчәкләр аларның холкына туры килә. Иң мөһиме букетны бизәүгә игътибар итәргә, бизәгәндә ачык аксессуарлар кулланырга кирәк. Ә ромашка, георгин, астралар кучкарларның күңеленә хуш килми.

**Үгезбозауларны** йомшак төстәге хризантемалар, герберлар, гладиолуслар белән сөендерү җиңел. Шулай ук алар кыр чәчәкләрен дә үз итәләр. Лалә, калла, орхидеяләр бүләк итәргә ашыкмагыз.

**Игезәкләргә** чәчәк букеты сайлавы бик җиңел. Иң мөһиме – букеттагы бутоннар саны 7 яки 21 булырга тиеш. Сары, ак, шәмәхә төстәге теләсә кайсы чәчәкне игезәкләр куанып кабул итеп алачак.

**Кысла** йолдызлыгында туучылар – нечкә күңелле кешеләр. Шуңа да аларга гөлчәчәк, калла, умырзая, мәк кебек чәчәкләрдән ясалган композицияләр ошый. Җылы төстәге пион, хризантема һәм кашкарый кысла йолдызлыгындагы гүзәл затларны илһамландыра.

**Арысланнар** сары яки кызыл, ал төстәге кыйммәтле букетларны үз итә. Алар өчен чәчәк бәйләмендәге аерым аксессуарлар мөһим урын алып тора, алар гадәти буларга тиеш түгел. Үзенчәлекле итеп, мәсәлән, чәчәк бәйләмен кәрҗингә, махсус тартмаларга урнаштырып, яфракларга матур сүзләр язып бүләк итсәң, арысланнар канәгать калачак.

**Кызлар** классик композицияләргә мөкиббән. Зәңгәр, яшел, алсу төсләр нәкъ менә аларныкы. Кызлар чәчәкнең тышкы күренешенә генә түгел, ә исенә дә игътибар итәләр. Астра, лилия, кыңгырау чәчәкләрен үз итәләр.

**Үлчәү** йолдызлыгындагы туташ-ханымнарга кызыл һәм сары төстән кала, башка төстәге чәчәк бәйләмен бирергә була. Иң мөһиме артык көчле исле булмаска тиеш.

**Чаяннар** зур эре чәчәкләрдән торган зәвыклы букетка шат булачак. Сары, кызыл, шәмәхә төсләрдән торган композиция бүләк итсәгез, алардан да бәхетле кеше булмас. Ә георгиннар, киресенчә, чаяннарның кәефен төшерә.

**Укчы** йолдызлыгындагы гүзәл затларга лалә, кашкарый кебек гади генә чәчәкне дә бүләк итәргә була. Тик букет бай һәм матур итеп бизәлгән булырга тиеш. Бәйләмдәге төсләр палитрасы да төрле булса, укчылар моны югары бәяли.

**Кәҗәмөгезләр** артык купшы чәчәк бәйләмен өнәми. Ул гади, тик зур, матур, тыгыз бутоннардан торган чәчәкләрдән төзелгән булырга тиеш.

**Сукоярларны** гадәти букет белән шаккатырып булмый. Аларга чәчәк сайлаганда, оригиналь чәчәкләр сайларга кирәк. Төсләр гаммасы да гадәти булмаска тиеш.

**Балыклар** ак төсләргә өстенлек бирә. Ак хризантема, гладиолус, гиацинт кебек чәчәкләрдән торган букет балыкларга күтәренке кәеф бүләк итә. Лалә һәм гербер чәчәкләреннән ерак торуыгыз хәерле.



кашкарый



дәлия



чалма чәчәк



энҗе чәчәк



## 1 ОКТЯБРЬ-ӨЛКӘННӘР КӨНЕ

Бу игелекле һәм якты бәйрәмдә өлкәннәребезгә булган йөрәк җылыбызны, игътибарыбызны тагын да арттырабыз.

1 октябрь гимназиябезнең беренчел профсоюз оешмасы ветеран укытучыларыбызны, озак еллар мәктәбебездә хезмәт куйган хезмәткәрләребезне бәйрәмнәре белән котлады: укучылар җырладылар, биеделәр, шигырьләр сөйләделәр, үз куллары белән ясалган ясалма чәчәкләр бүләк иттеләр. Бәйрәмнең икенче өлеше мәктәп ашханәсендә дәвам итте: ашханәдә эшләүче пешекчеләр өлкән буын хезмәткәрләребезне тәмле сый-нигъмәтләр белән сыйладылар, сәламәтлек һәм иминлек теләделәр.

1 октябрь көнне башлангыч сыйныф укучылары да үзләренең әби-бабалары өчен концерт күрсәттеләр:биеделәр, җырладылар, әкияттән өзек күрсәттеләр, матур итеп шигырьләр кхрсәттеләр.






## 5 ОКТЯБРЬ- УКЫТУЧЫЛАР КӨНЕ




1994 елдан бирле 100дән артык илдә 5 октябрь Укытучылар көне буларак билгеләп үтелә. Бу бәйрәм белем бирү өлкәсендә эшләүче һәркем өчен мөһим. Әлеге бәйрәмнең гамәлгә керүенә 1966 елның 5 октябрендә Парижда «Укытучыларның җәмгыятьтә биләгән урыны» темасына җыен үтүе сәбәпче булганлыгы билгеле. Нәтиҗәдә, ЮНЕСКО вәкилләре һәм Халыкара хезмәт оешмасы тарафыннан «Укытучы статусына кагылышлы тәкъдим»гә кул куела. Бөтендөнья укытучылар көне БМОбөтендөнья һәм халыкара көннәре исемлегенә кертелә.

Россиядә бу бәйрәмне 1994 елдан бирле 5 октябрьдә билгелиләр, аңа кадәр ул октябрьнең беренче якшәмбесенә туры китереп үткәрелде,

## РӘХМӘТ СИҢА, УКЫТУЧЫМ!

Иң беренче мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып, зур тормышка озатып соңгы кыңгырау чыңлаган көнгә кадәр безнең янәшәбездә һәрчак яраткан укытучыларыбыз атлый.

## Хөрмәтле мөгаллимнәребез!

Сезне һөнәри бәйрәмегез белән ихлас котлыйбыз! Барыгызга да исәнлек-саулык, бетмәс-төкәнмәс энергия, эшегездә яңа үрләр яулавыгызны телибез. Һәрчак укучыларыгызның рәхмәтләренә төренеп яшәгез! Тормыш сезгә бары тик «5»ле билгеләре генә куйсын!

*Мөхәррир-Гайнетдинова Э. Т.*

*Газета өчен материал туплаучылар һәм текстны җыючылар: 6,8 нче сыйныф укучылары*

*Безнең адрес: Буа шәһәре, Г. Исхакый урамы, 29*